| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР<br>422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ<br>422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15 |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 19 ноябре №23

Депутат Нәбиев А. М. вәкаләтләрен
вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешенең 2 пункты нигезендә, Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 39 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктына таянып, Кукмара шәһәр Советының дүртенче чакырылыш депутаты Нәбиев Азат Мөзәкир улының гаризасын карап, Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советының дүртенче чакырылыш депутаты, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең 6 нчы номерлы «Вокзал» сайлау округы буенча сайланган Нәбиев Азат Мөзәкир улының депутат вәкаләтләрен үз теләге буенча вакытыннан алда туктату турында язма гаризасы нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган дип санарга.
2. Әлеге карар аны кабул иткән көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «МО Кукмор» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәмТатарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре Мэры С.Д. Димитриев